**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Школьная ул., дом 30
с.Новый Арыш, 422656

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АРЫШ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 30нче йорт,
Яңа Арыш авылы, 422656

Тел.: (8-4361) 25-780, , факс: (8-4361) 25-780, эл.адрес: Nars.Rs.@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

11.09.2019 Яңа Арыш авылы №26

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Муниципаль хезмәт күрсәтүнен административ регламентларын раслау турында” 5 нче номерлы карары белән расланган күчемсез мөлкәт объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Федераль мәгълүмати адреслы система хакында һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” 227-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арышавыл җирлеге Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 3 номерлы карары белән расланган күчемсез мөлкәт объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге 13 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 кушымтаның 1.5 пунктында:

а) “адресация объекты – бер яки берничә күчемсез мөлкәт объекты, шул исәптән жир кишәрлекләре яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресларны бирү, үзгәртү, юкка чыгару кагыйдәләре белән каралган очракта, адрес бирелә торган башка объект;” җөмләсен “адресация объекты – капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте

тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;” җөмләсе белән алмаштырырга;

б) “”планлаштыру структурасы элементы" – зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;” җөмләсен
“планлаштыру структурасы элементы – җирлек, шәһәр округы яисә муниципаль районның авылара территориясенең бер өлеше ( квартал, микрорайон, район һәм башка шундый элементлар). Планлаштыру структурасы элементларының төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.” җөмләсе белән алмаштырырга;

в) “адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структурлаштырылган һәм шул исәптән планлаштыру структурасы элементының (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементының исемен, шулай ук адреслау объектын идентификацияләү (тәңгәлләштерү) мөмкинлеген бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы тамгаланышын үз эченә алган адресация объектының урнашу урынының тасвирламасы” җөмләсен “адрес – Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының исемен һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай ук адресация объектын идентификацияләү (тәңгәлләштерү) мөмкинлеген бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы тамгаланышын үз эченә алган адрес объектының урнашкан урынын тасвирлау” җөмләсе белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Х.С.Зарипов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ